**ГЛАВА
БАЛЫКЛЫ-ЧУКАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422655, с.Балыклы-Чукаево,
ул. Центральная, дом 9

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАЛЫКЛЫ-ЧҮКӘЙ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**

422655, Балыклы Чүкәй авылы,
Үзәк урам, 9 йорт,

Тел.: (84361) 26357, факс: (84361) 26357, e-mail:blc.rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.03.2018 ел Балыклы Чүкәй ав. № 6

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл торак пунктларында һәм авыл җирлегенең янәшә яткан территориясендә урнашкан су белән тәэмин итүнең тышкы чыганакларыннан янгын сүндерү максатларында елның теләсә кайсы вакытында су алу өчен шартлар булдыру турында

Россия Федерациясенең 1994 елның 21 декабрендәге “Янгын куркынычсызлыгы турында” 69-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 20 сентябрендәге “Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында” 947 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы Чүкәй авыл җирлегендәге су белән тәэмин итүнең тышкы чыганакларыннан елның теләсә кайсы вакытында су алу шартлары булдыру максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл торак пунктларында һәм авыл җирлегенең янәшә яткан территориясендә урнашкан су белән тәэмин итүнең тышкы чыганакларыннан янгын сүндерү максатларында елның теләсә кайсы вакытында су алу өчен янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларының һәм урыннарының исемлеген расларга (кушымта №1).

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл торак пунктларында һәм авыл җирлегенең янәшә яткан территориясендә урнашкан су алу өчен урыннарны һәм янгынга каршы тышкы су белән тәэмин итүне тикшерү һәм исәпкә алу Кагыйдәләрен расларга (кушымта №2).

3.Карар рәсми төстә бастырып чыгару (халыкка игълан итү) көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы Чүкәй авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча

урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районы Балыклы Чүкәй авылы, Үзәк урам, 8 йорт; Иске Арыш авылы, Үзәк урам, 23А йорт; Керәшен Казысы авылы, Титов урамы,11Б йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга. урнаштырырга

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балыклы Чүкәй авыл җирлеге
башлыгы А.М.Нуретдинова

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балыклы Чүкәй авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2018 елның 28 мартындагы
6 номерлы карарына
кушымта №1

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл торак пунктларында һәм авыл җирлегенең янәшә яткан территориясендә урнашкан янгынга каршы су белән тәэмин итүнең тышкы чыганакларыннан янгын сүндерү максатларында елның теләсә кайсы вакытында су алу урыннарының һәм янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларының исемлеге**

| № п/п | Су чыганагының урнашу урыны, адресы | Янгынга каршы су чыганагы |
|---|---|---|
| авылы | | |
| 1 | | |
| 2 | | |
| 3 | | |
| 4 | | |
| авылы | | |
| 5 | | |
| | | |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балыклы Чүкәй авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2018 елның 28 мартындагы
6 номерлы карарына
кушымта №2

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл торак пунктларында һәм авыл җирлегенең янәшә яткан территориясендә урнашкан су алу өчен урыннарны һәм янгынга каршы тышкы су белән тәэмин итүне тикшерү һәм исәпкә алу Кагыйдәләре**

1.Гомуми нигезләмәләр

1.1.Әлеге Кагыйдәләр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы Чүкәй авыл җирлегенең бөтен территориясендә гамәлдә һәм торак пунктларга хезмәт күрсәтүче су белән тәэмин итүгә җаваплы оешмалар, шулай ук идарәчелеккә һәм оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганагы булган барлык әбунәчеләргә дә үтәү өчен мәҗбүри.

1.2.Җирлекнең янгынга каршы тышкы су белән тәэмин итүе суүткәргечне, янгын сулыкларын, суэтем башняларын, шулай ук оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә сулары янгын сүндерү өчен файдаланыла торган бүтән табигый һәм ясалма су чыганакларын үз эченә ала.

1.3. Янгынга каршы тышкы су белән тәэмин итү чыганакларының техник торышына һәм күрсәткечләр урнаштыруга җаваплылык җирлекне су белән тәэмин итүгә җаваплы оешма яки чыганак аның карамагында булган әбунәче өстендә була.

1.4. Янгыннан саклау подразделениеләре янгын сүндерү өчен кирәк булган су алу (салу) өчен предприятиеләр һәм оешмалар биләмәсенә, шулай ук янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларының техник торышын тикшерүне гамәлгә ашыру өчен тоткарлыксыз керергә хокуклы.

2. Янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларының техник торышы, эксплуатацияләү һәм аларга карата таләпләр

2.1. Янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларының аларны янгыннарны сүндергәндә уңышлы куллану өчен даими әзерлеге төп хәстәрлек чараларын үткәрү белән тәэмин ителә:

-су белән тәэмин итүнең бөтен системасын, аларны төзеп, реконструкцияләп һәм ремонтлап бетергәч, җиренә җиткереп тәфтишле кабул итү;

- су чыганакларының хәл-торышына (халәтенә) системалы контроль;

-янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларын язгы-җәйге һәм көзге-кышкы чорларда файдалану шартларына үзвакытында әзерләү.

2.2. Янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганаклары төзек-житеш хәлдә булырга һәм янгын куркынычсызлыгы нормаларына ярашлы рәвештә күрсәткечләр белән җиһазландырылырга тиеш. Барлык янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларына 3,5 м дан да ким булмаган киңлектәге килү-керү юлы булдырылырга тиеш.

2.3.Саклау объекты территориясендә яки аңа якын-тирәдә (200 м радиуста) табигый яки ясалма су чыганаклары (инеш, күл, бассейн, градирня һ.б. лар) булганда, янгын автомашиналарын кую өчен каты капламлы 12х12 м дан кечкенә булмаган мәйданлы һәм елның теләсә кайсы вакытында су алырлык мәйданчыклары (пирслары) булган килү юллары салынырга тиеш.

2.5.Янгын сүндергәндә янгынга каршы түбән басымлы сүүткәргеч челтәрендә ирекле басым (җир өстедә) 10 м дан да ким булырга тиеш түгел.

2.6. Янгын сулыклары су белән тулган булырга тиеш. Сулыкларга каты капламлы һәм мәйданы 12х12 м лы борылу мәйданчыгы булган килү-керү юлы белән тәэмин ителергә тиеш.

2.7. Суэтем башнялары янгын техникасы су алу өчен 55 мм лы янгын ярымгайкалы җинкөпшәсе (патрубок) белән җиһазландырылырган булырга һәм аның янына килү өчен кинлеге 3.5 м дан ким булмаган каты капламлы юл булырга тиеш.

2.8.Пирслар (ике як-ягына килеп туктарлык корылма) ян яктан биеклеге 0,3 – 0,4 м булган нык киртәләнгән булырга тиеш.Су чыганагы ягыннан мәйданчыкта калынлыгы 25 см булган терәк борыс беркетелеп ныгытыла. Пирсның киңлеге бер, ике янгын сүндерү машинасы ирекле урнашуны тәэмин итәрлек булырга тиеш. Алар борыла алсын өчен пирс каршында каты капламлы үлчәме 12х12 м. булган мәйданчык ясыйлар. Пирс мәйданчыгының биеклеге суның иң түбән биеклегеннән 5 м дан артмаска тиеш. Пирс янында суның тирәнлеге 1 м дан ким булырга тиеш түгел. Кышкы чорда су туңганда 1х1 м үлчәмле бәке тишелә, ә пирс үзе кардан һәм боздан чистартыла.

2.9. Предприятиенең электр белән тәэмин итү механизмнары янгын насосларының электр двигательләрен өзлексез туендырып торуны тәэмин итәргә тиеш.

2.10.Су үлчәү җайланмаларының тирәли әйләндереп ала торган линияләрендә урнаштырылган электр кучергече белән эшермәләрнең (задвижки) эшкә яраклылыгы елга ике тапкырдан да ким булмаган санда тикшерелә, ә янгын насослары – ай саен.

2.11. Янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларын фәкать янгын сүндергәндә, занятиеләр, өйрәнүләр үткәргәндә һәм аларның эшкә яраклылыкларын тикшергәндә генә файдалану рөхсәт ителә.

3. Янгынга каршы су белән тәэмин итүне исәпкә алу һәм тикшерү тәртибе

3.1. Су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешмаларның җитәкчеләре, шулай ук әбунәчеләр катгый исәп алып барырга һәм алар карамагындагы янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларын Татарстан Республикасы буенча Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы Дәүләт Идарәсе Күзәтчелек эшчәнлеге һәм кисәтү эшләре идарәсенең Алексеевск һәм Балык Бистәсе районнары буенча күзәтчелек эшчәнлегенең районара бүлекчәсе (килештерү буенча) һәм "Татарстан Республикасы буенча янгынга каршы Федераль хезмәтнең 7 отряды" ФГКУ нең 128 номерлы янгыннан коткару часте (килештерү буенча) белән бергәлектә планлы тикшерүләр уздырырга бурычлылар.

3.2. Янгын сүндерү өчен файдаланырга мөмкин булган барлык су чыганакларын исәпкә алу максатында су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешма һәм әбунәчеләр "Татарстан Республикасы буенча янгынга каршы Федераль хезмәтнең 7 отряды" ФГКУ нең 128 номерлы янгыннан коткару часте (килештерү буенча) белән бергәлектә биш елга бер мәртәбәдән дә ким булмаган санда янгынга каршы су белән тәэмин итүдә инвентарьлаштыру уздыралар.

3.3. Янгынга каршы су белән тәэмин итүне тикшерү елга 2 мәртәбә үткәрелә.

3.4. Янгын сулыгын тикшергәндә тикшерелә:

-күренерлек урында билгеләнгән үрнәктәге күрсәткечнең булуы;

-янгын сулыгына тоткарлыксыз килү мөмкинлеге;

-су белән тулу дәрәҗәсе һәм аны тулыландыру мөмкинлеге;

-сулык янында су алу өчен мәйданчыкның булуы;

-эшермәләрнең (задвижка) герметиклыгы (алар булса);

-һава температурасы тискәре булганда бәкенең булуы (ачык сулыклар өчен).

3.5. Янгын пирсын тикшергәндә тикшерелә:

-күренерлек урында билгеләнгән үрнәктәге күрсәткечнең булуы;

- янгын пирсына тоткарлыксыз килү мөмкинлеге;

-янгын техникасы борылу өчен пирс алдында мәйданчыкның булуы;

-визуаль (күз йөртеп кенә) карап чыгу белән төп терәк конструкцияләрнең,түшәмәнең, киртәләүнең, терәк борысның хәл-торышы (халәте) һәм су алу өчен котлованның булуы.

3.6.Янгын сүндерү максатлары өчен яраклаштырылган су белән тәэмин итүнең бүтән чыганакларын тикшергәндә килү-керү мөмкинлегенең булуы һәм елның теләсә кайсы вакытында су алып булу мөмкинлеге тикшерелә.

## 4. Янгынга каршы су белән тәэмин итүне инвентарьлаштыру

4.1. Янгынга каршы су белән тәэмин итүне инвентарьлаштыру биш елга бер мәртәбәдән дә ким булмаган санда уздырыла.

5.5. Суүткәргечкә реконструкция ясаганнан соң аны комиссия тарафыннан кабул итү һәм су бирүенә сынау уздырыла.

## 6. Янгынга каршы су белән тәэмин итүне кышкы шартларда эксплуатацияләү үзенчәлекләре

6.1. Ел саен октябрь – ноябрьдә янгынга каршы су белән тәэмин итүне кышкы шартларда эшләүгә хәзерләү үткәрелә, аның өчен зарур:

- суны коелардан суыртып чыгару;

-сулыкдардагы су биеклеген, җылылык изоляциясе һәм бикләгеч арматураның төзеклеген тикшерү;

-янгын автомашиналарын куюһәм елның теләсә кайсы вакытында су алу өчен янгын сүндерү өчен булган су чыганакларына үлчәмнәре 12x12 м дан ким булмаган мәйданчыкны һәм килү-керү юлларын кардан һәм боздан чистартуны гамәлгә ашыру;

- янгын гидрантлары тәрәкләрен майлауны (буяуны) гамәлгә ашыру.

6.2. Янгын гидрантлары тәрәкләренең кату очрагында аларны җылыту һәм эшче халәткә китерү өчен чаралар күрү зарур.

4.2. Инвентарьлаштыру янгын сүндерү өчен файдаланырга мөмкин булган барлык су чыганакларын исәпкә алу һәм аларның халәтен һәм үзенчәлекле сыйфатларын ачыклау максатында үткәрелә.

4.3. Су белән тәэмин итүне инвентарьлаштыруны уздыру өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы Чүкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты карары белән составына авыл җирлеге җирле үзидарә органы, дәүләт янгын күзәтчелеге органы, җирлек биләмәсендә су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешма вәкилләре, әбунәчеләр кергән ведомствоара комиссия төзелә.

4.4.Комиссия һәрбер су чыганагын җентекләп тикшерү юлы белән ачыклый:

-янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларының төрен, санын һәм халәтен, аларга килү-керү юлының булу- булмавын;

-су чыганаклары санының кимү сәбәпләрен;

-сүүткәргеч магистральләрнең, участокларның диаметрын, челтәрләрнең тасвирнамәсен, суүткәргечләр кертелгән урыннарның санын;

-насосларның булу-булмавын, аларның халәтен;

-янгын гидрантларын (янгын краннарын) алыштыру планнарының үтәлешен;

-яңа сулыклар, пирслар, коелар төзүне.

4.5.Инвентарьлаштыру йомгаклары буенча инвентарьлаштыру акты һәм су чыганаклары торышын исәпкә алу ведомосте төзелә.

5. Янгынга каршы су белән тәэмин итүгә ремонт һәм реконструкция

5.1. Карамакларында төзек булмаган янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганагы булган су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешма, шулай ук әбунәчеләр ватыклык турында хәбәр алынганнан соң 10 календарь көн эчендә су белән тәэмин итү чыганагын ремонтларга бурычлылар. Капиталь ремонт үткәрелү яки су чыганагын алыштыру очрагында сроклар дәүләт янгынга каршы хезмәте белән килештерелә.

5.2.Суүткәргечкә реконструкция проектлаштыру оешмасы тарафыннан эшләнгән һәм дәүләт янгын күзәтчелегенең территориаль органы белән килештерелгән проект нигезендә ясала.

5.3. Реконструкция үткәргәннән соң янгынга каршы суүткәргечнең техник характеристикалары элек каралганнан түбән булырга тиеш түгел.

5.4. Ремонт үткәрү яки реконструкция ясау өчен суүткәргеч челтәре бүлемтекләрен өзгәнче бер тәүлек алдан ук карамакларында су чыганаклары булган су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешма яки әбунәчеләр билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы Чүкәй авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына һәм янгыннан саклану подразделениеләренә аларны файдаланып булмавы турында хәбәр итәргә бурычлылар, шуның өстенә өзелгән бүлемтекләрдә су җитмәүне каплаучы өстәмә чараларны күздә тотарга тиешләр.